# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «ӘҖМӘКӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
# МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ

**«12» октября 2020** **№2/1**

**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Әҗмәкәй» авыл җирлеге җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнары арасында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында килешүләр төзү тәртибен раслау хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы 4 өлеше, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Әҗмәкәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Советы

**КАРАР БИРДЕ**:

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Әҗмәкәй» авыл җирлеге җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнары арасында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында килешүләр төзү тәртибен расларга.
2. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында кушымта нигезендә килешү төзергә.
3. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка җиткерергә.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә (tukay.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http//pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.
5. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлеге Башлыгына йөкләргә.

Әҗмәкәй авыл җирлеге Башлыгы,
Совет Рәисе Р.Ф. Адиев

Татарстан Республикасы Тукай
муниципаль районы Әҗмәкәй авыл
җирлеге Советының 2020 елның
«12» октябрь 2020 номерлы
карарына кушымта

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Әҗмәкәй» авыл җирлеге җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнары арасында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында килешүләр төзү тәртибе

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Әҗмәкәй» авыл җирлеге җирле үзидарә органнары һәм «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге (алга таба – район) җирле үзидарә органнары арасында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында килешүләр төзүнең әлеге тәртибе «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон) нигезендә эшләнгән.

2. Җирлек җирле үзидарә органнары район җирле үзидарә органнары белән Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә җирлек бюджетыннан бирелә торган бюджетара трансфертлар хисабына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча үз вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында килешүләр төзергә хокуклы.

Шул ук вакытта район җирле үзидарә органнары «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, район җирле үзидарә органнарына җирлекнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл итү буенча аерым вәкаләтләрне тапшыру турында килешүләр нигезендә җирлек территориясендә авыл җирлегенең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыралар.

3. Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру инициативасы белән җирлекнең һәм районның җирле үзидарә органнары чыга ала.

4. Җирлек муниципаль берәмлегенең Башкарма комитеты үз иниципативасы буенча яисә район җирле үзидарә органнары инициативасын карап аны алган көннән 30 көчендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл итү буенча аерым вәкаләтләрне тапшыру турында җирлек Советы карары проектын әзерли.

5. Җирлек муниципаль берәмлегенең Башкарма комитеты җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча аерым вәкаләтләрне тапшыру турында җирлек Советы карары проектын җирлек Советына норматив хокукый актлар керткәндә билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда җирлек Советына кертә.

6. Җирлек Советы җирлекнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл итү буенча аерым вәкаләтләрне районның җирле үзидарә органнарына тапшыру турында карар кабул итә һәм кабул ителгән карарны карау өчен районның җирле үзидарә органнарына җибәрә.

7. Район Советы җирлек Советы карарын уңай кару нәтиҗәсендә җирлек җирле үзидарә органнары һәм район җирле үзидарә органнары арасында килешү төзелә.

Күрсәтелгән килешү билгеле бер вакытка төзелергә, аның гамәлдә булуын, шул исәптән вакытыннан алда, туктату нигезләрен һәм тәртибен билгели торган нигезләмәләрне, тапшырыла торган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле бюджетара трансфертларның әлеге өлештә күрсәтелгән еллык күләмен билгеләү тәртибен үз эченә алырга, шулай ук килешүләрне үтәмәгән өчен финанс санкцияләрен күздә тотарга тиеш.

Килешү проектын эшләү өчен һәр яктан тигез санда вәкилләрне кертеп, эшче төркем төзелергә мөмкин. Эшче төркем үз эше нәтиҗәләре буенча килешү якларының мәнфәгатьләрен максималь рәвештә исәпкә алучы килешү проектын әзерли.

8. Җирлек Советы җирлекнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл итү буенча аерым вәкаләтләрне район җирле үзидарә органнарына тапшыру турында карар проектын кире каккан очракта, районның инициатива юнәлткән җирле үзидарә органнарына алар инициатива белән чыккан мәсьәләне карау нәтиҗәләре хакында хат җибәрелә.

9. Килешүдә каралган вәкаләтләрне үтәү өчен кирәкле финанс средстволары бюджетара трансфертлар формасында бирелә.

Бюджетара трансфертлардан максатчан файдаланмаган очракта, алар җирлек бюджетына ун көнлек срокта кире кайтарылырга тиеш.

Тапшырыла торган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле бюджетара трансфертларны тапшыру максатында, тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле средстволар каралган район һәм җирлек бюджеты турындагы карарларга бюджет законнары нигезендә үзгәрешләр кертелә.

Тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен җирлек бюджетыннан бирелә торган бюджетара трансфертларны формалаштыру, күчерү һәм исәпкә алу Россия Федерациясе Бюджет законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыру өчен бирелә торган финанс средстволары ай саен тигез өлешләр белән күчерелә, әмма бер үк вакытта финанс средстволарының бөтен суммасын күчерергә мөмкин.

10. Вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыру өчен кирәк булганда, түләүсез вакытлы файдалану шартнамәсе нигезендә муниципаль милек тапшырыла.

Түләүсез файдалану шартнамәсе сроклы була һәм килешүнең гамәлдә булу срогына төзелә.

11. Күрсәтелгән килешүләр нигезендә тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен, районның җирле үзидарә органнары муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы карары белән каралган очракларда һәм тәртиптә үз матди ресурсларыннан һәм финанс средстволарыннан файдаланырга хокуклы.

12. Җирлекнең вәкаләтләр тапшырган җирле үзидарә органы тапшырылган вәкаләтләрнең үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыра, тапшырылган финанс средстволарыннан һәм матди ресурслардан файдалану турында кирәкле мәгълүматны сорый.

13. Килешүнең гамәлдә булуы вакытыннан алда туктатылырга мөмкин:

- яклар килешүе буенча;
- бер як үз йөкләмәләрен үтәмәгән яки тиешенчә үтәмәгән очракта,

берьяклы тәртиптә.

14. Килешүнең гамәлдә булуы вакытыннан алда туктатылган очракта, тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы район җирле үзидарә органы вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен тапшырылган файдаланылмаган финанс средстволарын, матди ресурсларны һәм милекне кире кайтара.

15. Килешүне үтәүгә бәйле бәхәсләр сөйләшүләр һәм башка килештерү процедуралары уздыру юлы белән хәл ителә. Бәхәсне сөйләшүләр яисә килештерү процедуралары уздыру юлы белән хәл итү мөмкин булмаган очракта, ул законнарда каралган башка тәртиптә каралырга тиеш.